


# Якташыбыз
# Галиев Әсрар Әбрар  улы

** 1938  елның 16 октябрендә Әлки районы Түбән Биктимер авылында колхозчы гаиләсендә  сигезенче бала булып дөньяга килә.*


**  Башлангыч мәктәпне  үз авылында ,  Ташбилге авылында җидееллык   мәктәпне тәмамлый.*
**   “Якты юл”, “Актай” хуҗалыкларында комбайнчы, тимерче ярдәмчесе булып эшли.*
** 1958 елда Лениногорск шәһәрендә  чыга торган “Ильич васыятьләре” газетасында  эшли.*
** 1959-1966 елларда Кемерово өлкәсе Прокопьевск   шәһәренең “ Красный углекоп” күмер шахтасында забойчы.*
** 1965-1971 елларда читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты    бүлеген тәмамлый. Укытучы булып эшли*
**  Әлки районы  “Коммунизм юлы” газетасы редакциясенең әдәби бүлегендә эшли.*
**  1973 елда яңадан Лениногорск шәһәренә китә.  Анда аның гаиләсеһәм өч баласы була.*

## *Әсрар Галинең  әдәби мирасы*

- *1980 елда  Татарстан китап нәшриятында беренче  “Төнге җыр” исемле китабы басыла*




- *1985 ел. “Казан утлары” журналының*
- *беренче санында  “Асыл кошым минем”*
- *исемле  повесте басыла.*
- **  1987 елда “Асыл кошым минем” китабы басыла.*




•*1992 елда “Көн яктысы” исемле   өченче китабы Татарстан китап нәшриятында басылып чыга.*




** 1996 елда “Гали батыр” трилогиясенең ике  томы басыла.*

•*1997 елда “Гали батыр” трилогиясенең*

•*тагын  ике томы дөнья күрә.*



*Әсрар Гали әсәрләренең геройлары – тормыш кадерен белгән, гадел, максатларына ирешүчән кешеләр. Игелекле, тормышның кадерен белеп, алга зур өмет-максатлар белән яшәгән чордашыбыз үзенең 60 еллык юбилеена илһамланып хәзерләнеп йөргәндә - 1998 елның 12 августында дөнья куйды.*

*«Кара бөдрә чәчле Әсрар Гали… Ул яшьтән үк көрәшергә яратты. Яшел аланда авылдашларын, дусларын, кунак егетләрен берәм-берәм сыртларына сала иде. Унынчы сыйныфта укыганда ук Әсраргали районда баш батыр булды. Ул чакта аңа 16 яшь иде. Мин дә абыйдан үрнәк алып спортны яратып үстем. Сәламәтлеге какшагач, күзләре бөтенләй начарлангач, биш кат күзлек киеп, баш күтәрмичә язды да язды…»*

*Бертугн энесе Корбангали Галиев*

*Шамил Маннапов*

*“Әсрар Әбрар улы Галиев булган барлык уңай һәм кимчелекле-йомшак яклары белән үзенчәлекле вә кабатланмас шәхес иде. Ул дөньяны, кешеләрне үзенчә итеп күрергә теләде, иҗаты белән дә, кылган гамәлләре белән дә шуңа омтылып яшәде.*

*Ни генә булмасын, аның күңеле - изгелектә, нияте яхшылыкта иде…”*

*Шамил Маннапов*

*«Сыйныфташым Әсрар Гали бик булган егет, бөтен нәрсәгә оста, искиткеч актив иде.»*

*Әсрар Галинең балачак дусты Марат Хәмитов*

*Әсрар ага, халкың, дусларың, авылдашларың, якташларың, каләмдәшләрең күңелендә*

*мәңге яшәрсең...*